Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№11 (62)

4 апрель 2013 ел

## Вакыйгалар эзеннән

Шушы көннәрдә **«СТУДЕНТЛАРНЫҢ ПРОФСОЮЗ ЛИДЕРЫ-2013»** конкурсы финалистлары игълан ителде. Алар арасындаКФУның Алабуга институты студентлары **ОЛЬГА САЛЬНИКОВА** һәм **КРИСТИНА МИНАСОВА** да бар. 11 апрельдә кызлар конкурсның финал өлешендә чыгыш ясаячак.

• • • •

29 март көнне Гыйльми советта университет структурасында **«Н.И.ЛОБАЧЕВСКИЙ** ис. **КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ ЛИЦЕЕ»** бүлекчәсен булдыру карары кабул ителде. IT-лицей белән бергә, алар белем бирү класстерының беренче баскычын тәшкил итәчәкләр. Ике лицей да федераль статус алачак. Яңа бүлекчә Казан шәһәре Вахитов районының «Казан федераль университеты каршындагы Н.И.Лобачевский ис. лицей» базасында оешачак. Лицейның учредителе дә үзгәрәчәк. Казан шәһәренең Белем бирү идарәсе башкарган вазифа Казан федераль университетына күчәчәк.

• • • •

**30 МАРТ КӨННЕ** КФУның Филология һәм сәнгать институтында рәсем һәм дизайн буенча **III ТӨБӘКАРА ОЛИМПИАДА ҮТКӘРЕЛДЕ**. Татарстан, Башкортстан һәм Киров өлкәсенең муниципаль белем бирү учреждениеләре кысаларында узган этапта дизайн буенча – 45 иҗади эш, рәсем буенча 20 эш сайлап алынган. Әлеге чараның максаты – рәсем сәнгате өлкәсендә балалар һәм яшүсмерләрнең потенциалын ачыклау, укучылар арасында профориентация эше алып бару.

• • • •

**3 АПРЕЛЬДӘ** Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтында «Яшерен хәзинә. Классик төрек иҗаты» күргәзмәсе кысаларында Төрек Республикасы Парламенты каршындагы Милли сарайның административ һәм финанс мәсьәләләре буенча директор Кемаль Кахраман әфәнде катнашында **«КЛАССИК ТӨРЕК ИҖАТЫ: ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ ЗАМАНЧАЛЫК» ФӘННИ-ГАМӘЛИ СЕМИНАРЫ УЗДЫ**. Семинарда төрек рәссамнары Төркиянең традицион сәнгать жанрлары: тезхибу (дивар бизәге), эбру (суда рәсем ясау), каллиграфия турында мәгълүмат бирделәр.

• • • •

**1 АПРЕЛЬДӘ** укучыларның Н.И.Лобачевский ис. **XIV ИДЕЛ БУЕ ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ТӘМАМЛАНДЫ**. Бу көнне җиңүчеләр КФУ вәкилләре кулыннан диплом һәм истәлекле бүләкләр алды. Берничә көн дәвамында 23 секциядә яшь сәләтләр үз эшләрен тәкъдир итте. Өстәмә рәвештә укытучылар һәм фәнни җәмәгатьчелекнең «Югары сыйныф укучыларының иҗади активлыгын үстерү» фәнни-практик конференциясе, фәннең актуаль мәсьәләләре буенча бәхәсләр, алдынгы галимнәр белән очрашулар уздырылды.

• • • •

Шушы көннәрдә Австриянең Вена университетында экспериментлар уздыру белән шөгыльләнүче психологларның 55нче конференциясе узды. КФУны Тел институтының алман теле кафедрасы доценты **Е.АЛЕКСЕЕВА** тәкъдир итте. Биредә ул Лейпциг университеты галимнәре белән хезмәттәшлектә уздырылган психолингвистик эксперимент нәтиҗәләре хакындагы доклад белән чыгыш ясады.

• • • •

**ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНЫҢ ИБЕРО-РОМАН ФИЛОЛОГИЯСЕ КАФЕДРАСЫ** бүген һәм иртәгә испан телен чит тел буларак укыту мәсьәләләренә багышланган **ХАЛЫКАРА СЕМИНАР УЗДЫРА**. Башка еллардагы кебек үк, чара Испан теле һәм мәдәнияте атналыгы кысаларында үтә. Әлеге семинарда Россия һәм Испаниядән килгән испан теле укытучылары тәҗрибә уртаклашачак, мастер-классларда катнашачак.

• • • •

**3-5 АПРЕЛЬ КӨННӘРЕНДӘ** «Казан ярминкәсе» үзәгендә **«БЕЛЕМ БИРҮ. КАРЬЕРА-2013» КҮРГӘЗМӘСЕ** үткәрелә. 13 тапкыр уздырыла торган бу чарада яшьләргә вакансияләр һәм уку-эш урыннары тәкъдим ителә.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Алия Галимуллина фотосы

# КФУ студентлары Франциягә китә

**Динара МИННЕКАЕВА**, хәбәрче

2 апрель көнне уку йортына Франциянең РФдәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле вәкиле Жан де Глиниасти җитәкчелегендә зур делегация килде. Алар республика, уку йорты җитәкчелеге һәм «Анри Пуанкаре» программасы стипендиатлары белән очрашты.

Казан федераль университеты Франциянең күп кенә белем үзәкләре белән хезмәттәшлек итә. Механика, менеджмент, тел-әдәбият, мәдәният өлкәләрендә студентлар француз телендә белемнәрен камилләштерә. Бу очрашуда «Анри Пуанкаре» стипендиаль программасына басым ясалды. Аның буенча килешү 2012 елның июнендә имзалана. Программа буенча елга бер мәртәбә Татарстан Республикасындагы 30 студент махсус стипендиягә ия булачак. Быел бу дәрәҗәле исемгә 8 студент лаек дип табылды. Аларның алтысы – безнең университет студентлары: Химия институтыннан Тимур Гыймадиев, Динара Чубукаева, Кара алтын һәм газ технологияләре институтыннан Зөлфия Гыйззәтуллина, Сергей Усманов, Физика институтыннан Ольга Образцова, Филология һәм сәнгать институтыннан Дарья Мельник. Алар Франциянең төрле вузларында бер уку елы дәвамында магистратура дәрәҗәсендә белем алачак.

Жюль Анри Пуанкарены тарихчылар иң бөек математик дип саный. Механик, физик, астроном һәм философ, Париж фәннәр академиясе башлыгы, дөнья күләмендәге утыздан артык академия әгъзасы, Петербург фәннәр академиясенең чит ил әгъзакорреспонденты булып торган, 500дән артык мәкалә һәм китап авторы. Аны, Гильберт белән беррәттән, соңгы математик-универсал дип атыйлар.

Очрашу барышында, стипендиатларны котлап, ректор Илшат Гафуров аларга зур уңышлар теләде. Ике як арасындагы хезмәттәшлек, эшләнгән эшләр, киләчәккә планнар белән таныштырды. Президент Рөстәм Миңнеханов белән узган очрашуга нәтиҗә ясап: «Ил башлыгы сүзләренә караганда, Франция белән алга таба хезмәттәшлек итү, беренче чиратта, белем бирү һәм фәнни-тикшеренү эшләренә нигезләнәчәк», – диде.

Вәкил, үз чыгышында, Франциянең бүген дөнья күләмендә тоткан урынына, аның Россия, Татарстан белән хезмәттәшлеге ныгуга басым ясады.

**Ахыры 2нче биттә.**

## Бездә кунак бар

# Төркия мәдәниятенә якынаябыз

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

2 апрель көнне КФУга Төркия Республикасының бөек Милли Җыелышы делегациясе килде. Делегация составында парламент вице-спикеры Стамбул провинциясеннән депутатлар Мераль Акшенер, Бурдур Хасан Хами Йылдырым һәм парламент администрациясе җитәкчесе Сивас Малик Әҗдер Оздемир.

**Ахыры 2нче биттә.**



Юлия Карпова фотосы

# КФУ студентлары Франциягә китә

Башы 1нче биттә.

Аның сүзләренчә, «Анри Пункаре» программасы буенча стипендияләр ике арадагы дуслык җепләрен тагын да ныгытачак. «Минем өчен Татарстанга килү – зур бәхет. Һәр очрашуда, биредә Франциягә зур игътибар бирелүен сизәм. Бу стипендиянең киләчәге дә өметле булыр, дип ышанам. Франция алдында да зур мөмкинлекләр ачыла: ул үзендә тирән белемле студентларны кабул итәчәк», – диде. Чарада катнашкан ТРның Мәгариф һәм фән министры урынбасары **Андрей Поминов**, үз чиратында, стипендиатларга мөрәҗәгать итеп: «Безнең илне, республикабызны Франциядә тиешле дәрәҗәдә тәкъдир итәрсез, дип ышанабыз», – диде.

Студентлар республика һәм уку йорты җитәкчелегенә чит илдә белем алу мөмкинлеге тудырган, француз телен, мәдәниятен өйрәнү өчен яхшы шартлар булдырганнары өчен рәхмәт сүзләре җиткерде. Филология һәм сәнгать институты студенты **Дарья Мельник**, барлык стипендиатлар исеменнән фикерләре, хис-кичерешләре белән француз телендә уртаклашты: «Бездә француз телен югары дәрәҗәдә өйрәнү өчен мөмкинлекләр бик күп. Бу уңайдан төрле чаралар, конкурс-фестивальләр үткәрелә. DELF имтиханын да үзебездә тапшыра алабыз. Шулай ук Парижның Сату-сәүдә итү халыкара имтихан тапшыру үзәге дә бар», – диде.

Очрашуны йомгаклап, ректор **Илшат Гафуров**: «Без тәрҗемә аша аңлашканда, стипендиатлар чыгышны рәхәтләнеп французча тыңлады», – диде. Студентлар Франциядән килгән башка галимнәр белән дә бик теләп аралашты.

• Сәяхәттән кайткач

# Исхакый тавышын ишеттек!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Тарих институтының татар халкы тарихы кафедрасы мөдире Искәндәр Аяз улы Гыйләҗев күптән түгел генә командировкадан кайтты. Ул Германиянең Тавыш архивында бик кызыклы һәм мөһим табышка - Гаяз Исхакыйның язмасына юлыккан. Искәндәр Аязович бу бәяләп бетергесез табышка ничек тап булган икән?



**– Искәндәр Аязович (*фотода*), Германиядә ике ай фәнни командировкада булып кайткансыз икән. Анда нинди ниятләр белән юл тоткан идегез?**

– Күптән түгел Берлиннан, фәнни командировкадан кайттым. Бу алдан уйланылган, планлаштырылган сәфәр иде. Мин I бөтендөнья сугышы вакытында Германия территориясендә булган мөселман хәрби әсирләре язмышын, тарихын өйрәнү өчен кирәк булган материал җыю өчен бардым.

**– Сезнең моңарчы игътибар үзәгегездә II бөтендөнья сугышы иде. Тема алыштыруыгыз очраклы рәвештә булдымы?**

– Әйе, моңа кадәр II бөтендөнья сугышын өйрәнү белән шөгыльләндем идем. Кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрем, китапларым, чыгышларым да күбрәк «Идел-Урал» легионы тарихына багышланган иде. Бөек Ватан сугышында татарлар, әсирлеккә төшкән татарларның, Германиядә булган татарларның язмышы – мине җәлеп иткән тема четерекле һәм кызык булып чыкты. Хәзер инде мин, I бөтендөнья сугышына күз салырга булдым, чөнки биредә шулай ук татарларга бәйле бик гыйбрәтле вакыйгалар байтак. Шунысын да онытмыйк: киләсе елда I бөтендөнья сугышы башлануга 100 ел тула. Бу юбилей матур тантана түгел инде, әмма уйлану өчен бер нигез булып тора. Ул сугыш тарихчылар һәм галимнәр өчен бүгенге көнгә кадәр икенче планда кала бирә. Ә уйлап карасаң, I бөтендөнья сугышы Россия, Европа, дөнья тарихында һәм, шул исәптән, безнең татар тарихында да гаҗәеп хәлиткеч роль уйнаган. Мисал өчен, 1917 елгы Октябрь революциясен бу сугыш нәтиҗәләреннән берсе дип санарга була, шул рәвешле, бөтен дөньяның манзарасы, картинасы үзгәрә. Шуңа күрә аның нигезләрен, нечкәлекләрен аңлау, барышын, үзенчәлекләрен белү, минемчә, бүгенге көндә бик тә актуаль.

**– Ике айлык тикшеренүләрегез бушка узмагандыр. Эзләп тапкан яңалыкларыгыз арасында иң үзенчәлеклесе кайсы булды?**

– Сугыш вакытында Германия үз территориясендә, ягъни Берлин янында, мөселман әсирләре өчен махсус лагерьлар оештыра. Англия, Франция һәм Россия гаскәрләрендә хезмәт иткәндә әсирлеккә төшкән солдатларны планлы рәвештә шунда туплый башлый. Алманлыларның конкрет максатлары да була: менә шушы кешеләрне үзләренчә тәрбияләргә, алар арасында пропаганда алып барырга. Шушы әсир мөселманнарны җиһатка өндәргә, ягъни үз илләренә каршы «изге» сугышта катнаштырырга телиләр. Бу исә, бөтен мөселман дөньясын кузгату дигән сүз. Ул план революционизация дип аталган. Монда алманнар мөселман картасын бик аңлы рәвештә файдаланырга уйлаганнар.

**– Бу материалларны табу өчен, күп вакытыгызны архивларда эзләнүләргә багышлагансыздыр?**

– Германиядә мондый лагерьларга караган чыганаклар шактый күп. Мин Берлин архивларында, китапханәләрендә эшләдем, төрле материаллар тупладым. Нигездә, болар – алман телендәге төрле характердагы рәсми документлар. Бераз татар телендә, бик аз рус телендә дә бар. Шулай ук Тышкы эшләр министрлыгы, Федераль, Берлин шәһәр архивында да булдым. Төрле институт, фәнни оешмаларда, Тавыш архивында эшләп, тавыш язмалары белән таныштым. Германиядә ул вакытта галимнәр, форсаттан файдаланып, әсирләрне фәнни яктан өйрәнгән. Бу бик бай материал һәм эзләнү өчен кызык юнәлеш булып тора. Мәсәлән, 1930 елда тел галиме Готхольд Вайль татар язмаларын алманчага тәрҗемә итеп, аны китап итеп тә чыгарган иде. Узган ел аны Казанда да бастырып чыгардылар.

**– Дистәләгән язмалар арасында сезгә кирәклесен табу күп сабырлык таләп иткәндер?**

– Архив эше – бик үзенчәлекле эш ул. Анда көтелмәгән әйберләр дә килеп чыга, бу нормаль күренеш һәм, минемчә, архив эшенең ләззәте дә шунда.

**– Гаяз Исхакый язмасына да шунда тап булдыгызмы?**

– Әйе, бәхетемә, әлеге Тавыш архивында музыка һәм телгә караган язмалардан тыш, 1932 елда Гаяз Исхакыйның тавышы яздырылган һәм шул язма сакланган. Мин аны Татарстанга, Казанга алып кайттым һәм киң җәмәгатьчелеккә ишеттердем. Ул шушы архивтагы язмалар җыелмасы белән бер фондка кереп калган.

**– Әлеге язма кемгә дә булса мөрәҗәгать рәвешендә эшләнгәнме?**

– Ул махсус эшләнгән язма. Аны хәзерге ситуация белән чагыштыру кыен. Бу – үзенә күрә техник прогресс күрсәткече. Сугыш вакытында әсирләрнең тавышын, җырларын, сөйләүләрен пластинкаларга яздырганнар. Ул вакытта, әлбәттә, озын язмалар ясый алмаганнар, шуңа күрә һәр язманың озынлыгы – 3-4 минут. Сизелеп тора: Исхакый кәгазьгә карап укый. Анда хата ясарга ярамаган, күрәсең. Ясаган очракта да, аны төзәтү техник яктан проблемалы булгандыр, дип фаразлыйм. Язманың эчтәлеге Идел-Урал дәүләте, аның халкына гомуми характеристикадан гыйбарәт. Шул ук вакытта, Гаяз Исхакый Идел-Урал дәүләтен олы ихтирам белән искә ала һәм аның киләчәге якты, дип өметләнә. Туган илен, туган халкын бик яратуы, аның киләчәгенә өмет белән каравы сизелеп тора.

Искәндәр Аязовичның шушы табышы ярдәмендә милләттәшләребез беренче тапкыр бөек шәхеснең тавышын ишетү бәхетенә ирешә. Бүгенге көн өчен бу бик зур вакыйга!

• Бездә кунак бар

# Төркия мәдәниятенә якынаябыз

Башы 1нче биттә.

**Мераль Акшенер** – төркия сәясәтчесе. 1956 елның 8 июлендә Измит провинциясендә туа. Ул Йылдыз техник университетында, Коджаели һәм Мармара университетларында укыта. Акшенер ханымның сәяси карьерасы, аны Стамбул провинциясенең Милли хәрәкәт партиясеннән депутат итеп сайлаганнан соң, 1995 елда башлана. Ул, 1996 елның 8 ноябреннән 1997 елның 30 июненә кадәр, эчке эшләр министры булып тора. 2007 елның 10 августыннан хәзерге көнгә кадәр – Төркия республикасы Милли җыелышының вице-спикеры.

Кунаклар Тарих музее, танылган Ленин аудиториясе һәм тарихи Актлар залы белән таныштыю Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтында Төркия делегациясен күптән түгел генә ачылган Төркия мәдәнияте үзәге таң калдырды.

Кунакларның төрек телен өйрәнүче студентлар белән очрашуы да күтәренке рухта узды. Ике як рәхәтләнеп аралашты, бер-берсен кызыксындырган сорауларга җавап алды. Чарада Татарстан республикасы Дәүләт Советы рәисе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе **Римма Ратникова**, Төркия республикасының Казандагы генераль консулы **Сабри Тунч Ангылы** да катнашты.

Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты директоры **Линар Латыйпов** фикеренчә, Төркиялеләрне институт Төркияне һәм төрек телен тирәнтен өйрәтә торган фәнни-белем бирү үзәге буларак кызыксындыра. Өстәвенә, 2014 елда Казаныбыз төрки дөнья башкаласы дип игълан ителде.

«Без югары квалификацияле белгечләр әзерлибез, шуңа күрә Төркия дипломатиясе турында лекцияләр студентлар өчен аеруча мөһим», – диде Линар Латыйпов. Шул максаттан уку йортына Төркия галимнәре лекция укырга киләчәк. Очрашуда Төркиянең Мәгариф министрлыгы тарафыннан Казан федераль университеты дипломнарын тану мәсьәләсе дә каралды. «Безнең университетны тәмамлаган Төркия студентларына бу яктан проблема булмасын өчен, Мераль Акшенер тиешле чаралар күрергә сүз бирде», – дип, фикерләре белән уртаклашты Линар Латыйпов.

Визит кысаларында кунаклар Төркия мәдәнияте күргәзмәсендә булачак. Шулай ук, делегация кичә Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтында узган Төркия мәдәниятенә багышланган фәнни-гамәли конференциядә дә катнашты.

• Мөнбәр

# «Darelfønүn» - кабат җиңүче!

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

29 март көнне КФУның Яр Чаллы институтында дүртенче тапкыр «МедиаПокорение» фестивале уздырылды. Анда без – «Darelfønyn» редакциясе вәкилләре дә катнаштык.



«МедиаПокорение» фестивале – Россиядәге яшь журналистлар өчен уздырыла торган иң абруйлы конкурсларның берсе. Биредә катнашучыларга үз көчләрен сынап карау һәм тәҗрибә уртаклашудан тыш, танылган журналистлардан яңа һөнәри күнекмәләр алу мөмкинлеге дә бирелә. Быел да конкурс илебезнең төрле төбәкләреннән яшь каләм тибрәтүчеләрне үзенә җыйды.

Башка еллардагы кебек үк, фестиваль теркәлүдән башланып китте. Оештыручылар әйтүенчә, конкурста катнашу өчен, Россиянең егермеләп шәһәреннән туксаннан артык гариза кабул ителгән булган. Бу, үз чиратында, яңа танышлар, дуслар табарга менә дигән мөмкинлек.

Фестивальнең ачылу тантанасында безне филология һәм журналистика факультеты деканы **Наталья Федотова** сәламләде. Аның изге теләкләре барлык катнашучыларның күңеленә хуш килде. «Яңа гасыр» телевидениесенең баш продюсеры, жюри рәисе **Миләүшә Айтуганова** исә, яшь журналистларны уңышка ирешү серләренә төшендерде. «Йолдыз булу өчен башка йолдызларны кабызырга кирәк», – диде.

Фестиваль ачылганнан соң, катнашучылар Интернет-ММЧ, дизайн, радио, әдәбият һәм универсаль журналистика буенча мастер-классларда белемнәрен күтәрде, күнекмәләр туплады. Мастер-класста катнашкан һәр кешегә сертификатлар тапшырылды.

Фестивальнең бүләкләү тантанасы актлар залында дәвам итте. Төрле номинацияләрдә җиңү яулаган катнашучыларны жюри әгъзалары, танылган журналистлар, шул өлкә белән бәйле шәхесләр тәбрикләде.

Безнең «Darelfønүn» газетасы «Иң яхшы корпоратив басма» номинациясендә **I дәрәҗәле дипломга** лаек булды. Бу җиңү редакциябез хезмәткәрләренең һөнәребезгә ни дәрәҗәдә бирелгәнлеген тагын бер кат исбатлады. Мондый уңышларыбыз алга таба күп булыр дигән өметтә калабыз!

• Сәнгать

# «Манзара»да гүзәл манзара

Нәҗип НӘККАШ,
рәссам-хаттат

Шушы көннәрдә Филология һәм сәнгать институты бинасында (Татарстан урамы, 2), китапханә белән янәшәдә, «Манзара» дип исемләнгән сынлы сәнгать галереясе ачылды. Бирегә, сынлы сәнгать һәм дизайн кафедрасының мөдире Расыйх Сәләхов әйтүенчә, төрле атаклы рәссам, дизайнер, һөнәрчеләрнең һәм шушы институт студентларының алмашынып тора торган күргәзмәләре булачак.



Бик хаклы рәвештә, беренче булып, бу урында Татарстанның халык рәссамы Рифкать Вахитовның шәхси күргәзмәсе ачылды. 75 яшьлек юбилеен билгеләп үтүче бу милли рәссам соңгы елларда сынлы сәнгать һәм дизайн кафедрасында студентларга белем бирә, үзенең зур тәҗрибәсен, сынлы сәнгать серләрен һәм нечкәлекләрен яшьләргә тапшыра.

Зур булмаган бу галереяда рәссамның күпьеллык иҗат мирасының бер өлеше генә урын алды. Шулай да төрле жанрдагы әсәрләр Рифкать аганың иҗат үзенчәлекләрен бик төгәл итеп күз алларга булыша.

Биредә авторның киндергә төшерелгән рәсем сәнгате әсәрләре: портрет, пейзаж, натюрморт жанрындагы эшләре куелган. Аларның һәркайсы татар милләтенең, халкының тарихын, мәдәниятен, яшәешен, көнкүрешен һәм аны урап алган мохитне чагылдыра. Бу миллилек теманы, персонаж-геройларны сайлап алуда да, композиция, төс-төсмерләр, сызыклар бирелешендә дә күренеп тора. Рәссам соңгы елларда өстенлек ала барган глобализм күренешләреннән – абстракционизм, модернизм, авангардизм агымнарыннан ерак тора, ул – ачык реалист. Бу бигрәк тә портретларда ачык чагыла: беренчедән, ул чынбарлыктагыча, төгәллек белән реалистик образлар бирә, икенчедән, шул портрет фонында шартлы декоратив композицияләр ясый. Бу бигрәк тә татарның атаклы шәхесләре: аһәңсаз (композитор) Салих Сәйдәшев, җырчы Илһам Шакиров, дәүләт эшлеклесе Минтимер Шәймиев портретларында чагыла. Портрет охшашлыгы, образның эчке дөньясы, холкы төгәл бирелү белән беррәттән, картинаның фоны символик, метафорик мәгънәләргә бай.

Мәсәлән, татарның сөекле аһәңсазы – Салих Сәйдәшев портреты. Киндер яссылыгында киемннән, гәүдә торышы һәм йөзеннән чын зыялылык бөркелеп торган чибәр татар ир-егете сурәте. Шартлы фонда исә, композиторның әсәрләре куелышын чагылдырган афишалар. Алар төрле графикада: гарәп, латин һәм кириллица хәрефләре белән башкарылганнар. Менә шушы атрибутлар, әллә ни күзгә ташланып тормый торган детальләр Сәйдәшнең нинди катлаулы күчеш чорында яшәгәнен, ун ел эчендә ике мәртәбә язуы алышынган, борынгы мирасыннан мәхрүм калган татар милләтенең фаҗигасен күрсәтеп тора. Әйе, гамьле, уйлы һәм мәгънәле картина...

Татарстан Җөмһүриятенең беренче Президенты, Илбашы Минтимер Шәймиевнең дә портреты шактый үзенчәлекле. Төгәл охшашлык белән башкарылган портрет тулысынча шартлы фонда, шартлы киемнәрдә бирелгән. Милли киемле монументаль фигура Татарстан табигате, татарның олуг, тарихи шәһәрләре Болгар һәм Казан фонында сурәтләнә. Илбашының кулында тезгенләнгән ат, янында колыны да бар. Бу – Җөмһүрият белән идарә итү Илбашы кулында һәм аның киләчәге өчен дә ул җаваплы булуына ишарә. Арткы планда – җилдерәп чабып бара торган атлар. Бу исә – вакыт алмашынуы, атлар белән бәйле төрки-татар күчешләренең символы. Тагын да арттарак борынгы Болгар һәм Казан шәһәрләре күренеше, болары татарның дәүләтле һәм шәһәрле халык булуын күрсәтеп тора.





Плакатка тартым бу портретлы картина Көнчыгыш миниатюраларына охшаш, ник дигәндә, күп планлылык, шартлылык, һава һәм сызык перспективаларын сакламыйча панорама бирү нәкъ менә миниатюраларга хас.

Миниатюра сәнгатенең йогынтысы рәссамның башка әсәрләрендә дә сизелеп тора. Бу исә аның шактый еллар Урта Азиядә, Ташкент шәһәрендә яшәве, үзенең остазы – татар рәссамы, монументалист Чыңгыз Әхмәров тәэсире белән бәйле булса кирәк.

Күргәзмә әле 20 апрельгә кадәр эшләячәк. Югары сәнгати әсәрләр белән танышырга, тирән мәгълүмат һәм эстетик ләззәт алырга ашыгыгыз.

• Мәсьәләгә бер караш

# Акчаң булса, син - «отличник»?

Ләйсән ИСХАКОВА,
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



Яз – карлар эреп, җылы яктан кошлар кайткан чак кына түгел, ә студентларның курс эшләрен тапшыру, диплом эшләрен әзерләү вакыты да. Шуңа Казанда хәзер чат саен «курс эшләре, рефератлар, дипломнар» дип язылган төсле игъланнар эленгән. Укырга җәяү барган юлда һәр багана саен ябыштырганнар. Университет тирәсендә дә шундый ук эчтәлекле кәгазь кисәкләре өлешеп торалар. Җаның теләгән темага фәнни хезмәт язып бирүчеләр табыла – акчаң гына булсын. Әбәяләр төрле җирдә төрлечә. Кайберләрендә кимендә 500 сум таләп ителсә, икенчеләре студенттан бер стипендия бәясен сорый. Беркөн, кызыксынып, мин дә игъланнардагы телефоннарга шалтыратып карарга булдым.

Түбән бәядән курс эше язып бирергә өметләндергән бер игъландагы кәрәзле телефон номерына шалтыраттым. Курс эше өчен минималь бәя 800 сум икән. 2-3 көндә әзер була, дип ышандырдылар. «Мәгълүмат интернеттан алынмый, үзебез язабыз», – диделәр.

Икенче игъландагы номер белән дә элемтәгә чыктым. Монысы җитдирәк тоелды. Исеменнән күренгәнчә, мәгариф үзәге. Биредә дә фәнни эшләрнең авторлар язганлыгына басым ясарга тырыштылар. Ләкин шул ук вакытта: «Сезгә кирәкле темага авторлар язган фәнни хезмәтләрдән тыш, әзер курс эшләре дә бар», – дип өстәделәр. Кимендә – 700 сум, тик теманың авырлыгына карап, бәяне билгеле бер процентка арттыралар. Әмма сорагач, теманың җиңеллек-авырлыгын ничек билгеләүләрен әйтә алмадылар. Диплом эшен, кимендә, 6 мең сумга сатып алып була. Нигездә, курс эше бер атнадан, диплом бер айдан әзер була икән. Өстәмә рәвештә түләсәң, фәнни хезмәтне син теләгән вакытка да өлгертә алалар. «Татар телендә фәнни эшләр бармы?» – дип сорагач, башта, юк, дисәләр дә, соңыннан: «Өстәмә рәвештә түләгән очракта шәхси авторлар ярдәмендә татарчаны да табып була», – диделәр.

Өченчесендә дә шалтыраттым. Монысы укыту үзәге икән. Биредә дә авторлар язган фәнни эшләргә өметләндерделәр. Шулай ук бер атнадан әзер була икән. Бер авырлыксыз татарча курс эше дә язып бирәләр. Бәясе генә гадәттәгедән ике тапкыр артык була, дип белдерделәр. Диплом эшенең минималь бәясе10 мең сумны тәшкил итә. Татарча дипломның бәясен гади арифметик исул белән чутлап чыгару кыен түгел, ким дигәндә, 20 мең таләп ителәчәк. Уку йортының исемдәрәҗәсе дә зур әһәмияткә ия. Дәрәҗә югары булган саен, диплом эшенә «очачак» акча күләме дә зуррак.

Сораучысы булгач, тәкъдим итүчесе дә табыла дигән гыйбарә бар бит. Дистәләгән укыту, мәгариф үзәкләре һәм шәхси авторларның һәммәсе студентка «ярдәм итәргә» әзер. Димәк, студентлар фәнни эшләрне үзләре язарга ашкынып тормый, җаен китереп, сатып алу ягын карыйлар. Ләкин моңа аларның стипендия акчасы гына җитмәве көн кебек ачык. Чыдаган әти-әни кесәсенә рәхмәт.

Югарыда китерелгән бәяләрне һәм «Белем һәрвакыт синең белән. Ул акчадан кыйммәтрәк», дигән гыйбарәне искә алып, үзем язган курс эшемнең әзер булуына тагын бер кат чын күңелдән сөенеп, иркен сулап куйдым.

# Белем алуның үз бәясе

Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Дус кызым көлә: «Студент кеше кибеткә кергәч, башта бәя карый, аннары гына аласы әйберенең сыйфатына игътибар итә!» Әйе, шулай эшлибез. Ә кая барасың? Санаулы гына акчаны «кысып», акыл белән тотмасаң, сумнар агым су кебек бик тиз агып китә, сизми дә каласың.

Белгечләр сүзләренә ышансаң, студентларга азык-төлек алыр өчен генә дә аена 3-3,5 мең сум тирәсе акча кирәк икән. Тик бу ризыкны өйдә генә ашап торганда. Ә тамагыңны вуз ашханәсендә туйдырырга туры килсә, акча күбрәк кирәк булачак. Студент бюджетының бу пункты да арзанга төшми. Мәсәлән, аш, ботка һәм чәй алганда, кимендә 60 сум кирәк. Ә тәмлерәк әйбергә күзе төшкәннәрнең төшке ашлары 100 сумнан да артып китәчәк. Вузга көн саен йөрүебезне исәпкә алганда, атнасына ашханәләргә күпме акча киткәнен исәпләп чыгару авыр түгел.

### Җәяү йөрү яхшырак

Акча җил кебек сызгырып китә торган тагын бер урын – транспорт. Тулай тораклары университет янында урнашкан студентлар бәхетле, алар укырга җәяү генә йөри. Тик андыйларны күп димәс идем. Хәзер вузда укучыларның күбесе бик макталган «Студентлар авылы»нда тора. Шәһәр читендә урнашкан әлеге торактан югары уку йортына бару өчен егет-кызларга автобуска яисә метрога утырырга кирәк. Билет бәясен 19 сум дип исәпләгәндә, барып кайту өчен генә көненә 38 сум акча китә, бу аена 1140 сум дигән сүз. Тормыш булгач, йомыш-мәшәкатьләре дә гел чыгып тора бит, җәмәгать транспортына көненә өч-дүрт мәртәбә утырган чаклар да булгалый. Аена бер мәртәбә булса да туган якларга кайтып киләсе килә. Шулай булгач, юлга киткән акчалар да хәйранга җыела.

### Язу, сызу, бастыру

Уку елы башында әле без язу-сызу кирәк-яракларны да алабыз. Аңа киткән акчаны исәплик. Лекцияләр яза-яза, аена 3-4 паста бетә. Аңа өстәп, рефератлар, курс эшләре, докладлар язуга киткән кәгазь-папкаларга хәйран акча чыга. Ярый әле, мин гуманитар факультетта укыйм. Төзелеш институтында укучы танышым сүзләренә караганда, аларның сызымнарга киткән акчалары бихисап икән. Менә шуларның бөтенесен санасаң, аена уртача 200-300 сум. Бу суммага кәрәзле телефон, интернетка түләгән акчаларны да кертсәк...

### Укырга һәм... укырга

Башкалада яшәгәч, күбебезнең төрле ял итү үзәкләренә, киноларга, кафеларга да баргалыйсы килә. Вакытны күңелле һәм файдалы үткәрүгә киткән акчаларны исәплик. Мәсәлән, кино бәясе бүген, кимендә, 100 сумнан башлана, әле анысы да иртәнге сеанска килсәң. Ә кичкә таба бәяләр күтәрелә. Киного баргач, поп-корн яки эчәргә су да алмыйча калмыйсың. Төрле күргәзмәләрне, концертларны үз итүчеләр дә бар. Андыйларга акчаларын тагын да күбрәк чыгарып салырга туры килә, чөнки яхшы күргәзмәләргә керү бәясе 200 сумнан башлана. Шулай итеп, уртача алганда, ял итү һәм иҗади яктан үсү өчен, студентка айга 400-500 сум чамасы кирәк.

### Нәтиҗә

Ә хәзер югарыда исәпләнгән акчаларны кушып карыйк.

Тамак туйдыру – 4500 сум.

Язу-сызу әйберләре, интернет һәм телефонга – 1200 сум.

Ял итү – 500 сум.

Юлга киткән акча – 1100 сум.

Тулай торакта яшәү – 100 сум.

Нәтиҗә: 7400 сум

Бу санга карап-карап тордым да, гади студент стипендиясен кузалладым. Бүгенге көндә ул 1200-1300 сум чамасы. 7 мең сум белән бер дә чагыштырырлык түгел! Студент акчасына бүген җан асрарга гына була шул...

• Әдәби сәйләннәр



Бүген игътибарыгызга татар филологиясе бүлеге студенты **Гөлчәчәк Хөснуллина** иҗатын тәкъдим итәбез. Балык Бистәсе районы Биектау авылында туып үскән кыз, үзен белә башлаганнан бирле, шигырьләр яза. Кама елгасы буенда уйланып йөргәндә, Чистайның назлы җилләрендә тибрәлеп, Шомбыт елгасында яланаяк су ерганда үзенә илһам ала икән ул. Соңгы араларда үзе өчен янарак жанр – бәетләр язу белән шөгыльләнә.

## Яз киләме быел?

*Язлар быел элек булган*
*Язларга охшамаган.*
*Табигатькә яз килергә*
*Мин, ахры, ышаналмам.*

*Кышның китәсе килмиме,*
*Яз белән сыный көчен.*
*Мондый булгач бу язлары,*
*Озын булмасмы көзем?*

*Аңа кадәр ерак әле,*
*Тик шулай да уйлата.*
*Кулга тагын каләм алдым,*
*Ә кыш буран уйната.*

*Барча халык аптырашта,*
*Иртән торып чыгуга.*
*Кичә генә кояш иде,*
*Кар яуган таң тууга!!!*

## Авыл кызлары, имеш...

*Авыл кызы дип еш кына,*
*Үртәгән була күпләр.*
*Ышанмагыз, Сез аларга,*
*Бу сүзләр бит – чүп сүзләр!!!*

*Безнең үргә бик күпләргә*
*Җитәргә кирәк әле.*
*Бездә генә курку белмәс,*
*Бик көчле йөрәк әле.*

*Авыл баласы булуның*
*Начар ягы бар, дисәң,*
*Башкача сайрап китәрсең,*
*Минем авылга килсәң...*

## Туган якка кайттым тагын бер...

*Ян-ягымда минем белән бергә,*
*Туган якка кайта кешеләр.*
*Минем кебек барлык кешеләр дә*
*Хәл белергә кайта иделәр.*

*Минем юлым бүген шактый озын,*
*Ә кемнәрдер күптән авылда.*
*Алып кайткан әз-мәз күчтәнәчне*
*Чәй эчкәндә куя алдына.*

*Менә мин дә кайтып җиттем инде,*
*Басып торам өем каршында.*
*Мине каршыларга әткәй чыккан,*
*Хәтта кимәгән ул башына.*

*Әнием дә чыгып килә әнә,*
*Бәлеш салган, чыккан исләре.*
*Искә төште шул бәлешне ашап,*
*Бергә узган якты кичләре...*

*Башларына ак яулыгын япкан,*
*Дәү әнием тота куллардан*
*Минем өчен дога укып шулай,*
*Кайтуымны көтә юллардан...*

*Бүлмәсеннән йөгереп килеп чыга,*
*Сагынган шул мине сеңлем дә.*
*Якыннарым, Сез генә дә түгел,*
*Сагынганмын икән үзем дә.*

*Гаиләң белән бергә шулай җыелып,*
*Чәй эчүләр булсын һәрвакыт.*
*Әти-әни, дәү әниләр янына*
*Кайтып килик шулай җай табып.*

• Сораштыру

Ә СИН ҖӘЙГЕ СЕССИЯГӘ КҮПМЕ ВАКЫТ КАЛГАНЫН БЕЛӘСЕҢМЕ? БЕЛСӘҢ, АФӘРИН, БЕЛМӘСӘҢ, СИН СТУДЕНТ ТОРМЫШЫННАН КҮПКӘ АРТТА КАЛГАНСЫҢ, ЧӨНКИ ҖӘЙГЕ СЕССИЯ МЕНӘ-МЕНӘ БАШЛАНЫРГА ТОРА. Ә БУ ИНДЕ КИШТӘ-КИШТӘ КИТАПЛАР, ЛЕКЦИЯ ДӘФТӘРЛӘРЕ, ТАЛКЫНАСЫ НЕРВЛАР ҺӘМ ЙОКЫСЫЗ ТӨННӘР ДИГӘН СҮЗ... БЫЕЛ ЯЗ СОҢГА КАЛЫП КИЛСӘ ДӘ, СЕССИЯ КӨТТЕРЕРГӘ ТЕЛӘМИ, Ә ТИЗРӘК, ҮЗ ЭШЛӘРЕН ТӘМАМЛАП, БЕЗНЕ ОЗЫН ҖӘЙГЕ ЯЛЛАРГА ОЗАТЫРГА АШЫГА.

# «Мин майда ял итәчәкмен... Быел!»

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

Универсиадага бәйле рәвештә, бу семестр, башкаларына караганда, күпкә кыска булды. Кыскартылган срокта булса да, тиешле белемне алдык. Узган елларда җәйге сессия июнь-июль айларына кадәр дәвам иткән булса, бу сессия 1 майга тәмамланырга тиеш, дип көтелә. Һәр нәрсәнең уңай һәм тискәре яклары булган кебек үк, монда да шул вәзгыять. Дөрес, бу студенттан аеруча зур көч һәм тырышлык таләп итәчәк. Күп материалны үзлектән өйрәнү, зачет-имтиханнарга әзерләнү вакыты кысан булу кайбер студентларга төрле кыенлыклар китеререргә мөмкин. Ләкин «хезмәте каты – җимеше татлы» дигәндәй, ныклап тырышканнан соң, 4 айлык каникуллар һәр студент өчен бик татлы җимеш булыр.

**Нурсөя Минзина** (Татар филологиясе бүлеге): «Минемчә, тиз темп белән уку бик үк яхшы әйбер түгел. Бер көнгә күп дәресләр туры килә, ял итәргә вакыт та юк. Шул шимбәгә авылга кайтып килсәң инде, анысына да китап-дәфтәрләр кыстырып. Икенче яктан караганда, без әти-әниләр янында озаграк торачакбыз. Минемчә, ул яллар бик кызык, яхшы, файдалы үтәргә тиеш. Җәйге Универсиада вакытында волонтер булырга исәп. Ә калган вакытта, бераз акча эшләү нисбәтеннән, эш эзләрмен. Бөтен студентларга да сабырлык телим, имтиханнарын яхшы гына бирсеннәр».

**Раил Садретдинов** (Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты): «Әлбәттә, бу ялның үз нюанслары бар. Бер яктан, студентлар депрессия халәтендә имтиханнар тапшырырга мәҗбүр. Ник дисәң, язгы талчыгу, һава торышының үзгәреп торуы сәламәтлегебезгә нык тәэсир итә. Җитмәсә, тулай торактан китү, кая барырга, нишләргә белмәү дә өстәлә. Икенче яктан, бер михнәтнең бер рәхәте була дигәндәй, җәйге ялыбыз озаккарак сузылачак – бу үзе бер сөенеч».

**Рамил Газизов** (Сәнгать бүлеге): «Мин бу ситуациягә бик уңай карыйм. Студентларның ял итү өчен күпме буш вакыты булачак бит!!! Ә сессиягә килгәндә, безнең бүлекнең талантлы студентларына зачет-имтиханнарны тапшыру авыр булмаячак. Ел дәвамында тырышып укыганнар, төрле чараларда актив катнашканнар сессияне бик җиңел




ябачак, дип уйлыйм. Шулай да көн аралаш имтихан тапшыру кайбер кыенлыклар китереп чыгарырга мөмкин. Укуның, сессиянең шундый темпта узуы гына күңелне төшерә. Кайвакыт, Универсиада Алла микән әллә, дигән уй килә».

**Алия Әхмәтҗанова** (Физика институты): «Мин үзем әлегә күп минуслар күрмим. Киләчәктә кирәк булачак белемнәр генә зыян күрмәсә инде. Бөтен җирдә тоташ плюслар: лаборатор эшләр кимрәк, мөгаллимнәр йомшаграк, материалның мөмкин кадәр нгезләрен генә бирәләр, артык төпченүләр булмагач, аңлавы җайлырак. Һәм, ниһаять, Яңа ел, Сабантуй ише бәйрәмнәр безне дә урап үтми. Миңа болай уку бик ошады, гел шулай булса, шәп булыр иде».

• Дөнья үзебезнеке

# Моңсу малай

Яшәгән бер Сабый. Ул еш кына моңсуланып һәм күңелсезләнеп йөри торган булган. Аның әти-әнисе, башка кешеләр кебек үк, күп эшләгән, шуңа күрә Сабый бөтен вакытын әбисе белән үткәргән. Ул әти-әнисен бик сагынган һәм аның өчен бары тик алар белән уздырган яисә алар бүләк биргән көннәр генә шатлыклы булган. Әмма әти-әни белән аралашу мөмкинлеге – бик сирәк күренеш, ә бүләк алганнан соңгы шатлык, никтер, бик тиз юкка чыга икән.

Бервакыт, кич белән, инде йокларга яткач, сәер тавыш ишетелә. Малай куркырга өлгергәнче, аның алдында әкияти Эльф пәйда була.

- Кем син? – дип сорый Сабый.

- Мин моңсу балаларга шатлык китерә торган Эльф, – дип җавап бирә таныш түгел тавыш.

- Димәк, син миңа бүләкләр алып килдең? Әллә иртәгә әти-әнием минем белән көне буе уйнаячакмы?! – дип куана Сабый.

- Юк, – дип җавап бирә Эльф.

Шуннан соң Сабый тагын боегып кала.

- Монда кара әле, Сабый, – ди Эльф. – Синең әти-әниеңә эшләргә кирәк, алар синең өчен бар көчләрен куя. Бүләкләргә килгәндә, кара, алар синдә күпме! Нишләп соң син ямансулыйсың? Син бәхетле түгел мени?

- Мин бүләкләрне алганда бик сөенәм, әмма аннан соң, нишләптер, шатлык югала һәм бүләкләр куандырмый башлый, – дип җавап бирә Сабый моңсу гына.

- Минем сиңа шатлык һәм бәхет китерә торган бер әйбер күрсәтәсем килә. Әмма безгә башта кечкенә эльфлар иленә барып кайтырга туры килер.

Эльф тылсымлы сүзен әйтә һәм алар әкият патшалыгына килеп тә җитәләр. Тирә-якта – матур өйләр, кечкенә эльфлар уйный торган чәчәкле аланнар. Эльфлар бәхетле һәм йөзләрендә елмаю балкый.

- Алар нигә шатланалар? – дип гаҗәпләнә Сабый.

- Аларны бераз күзәтсәң, үзең аңларсың, – ди Эльф серле генә.

Малай йорттан йортка, аланлыктан аланлыкка күзәтеп йөри башлый. Ул бер олырак Эльфның кечерәге белән уйнавын, икенчесенең әти-әнисенә бүләк ясавын, кемнеңдер өйдә тәртип урнаштыруын, кайсыныңдыр башкаларга шаян, күңелле хикәяләр язганын күрә. Һәммәсе дә башка берәү өчен нидер эшли. Сабый, кашларын җыерып, бер үзенең Эльфына, бер тирә-ягына карап куя.

- Син эшнең нидә икәнен аңладыңмы? Алар бөтенесе дә башкаларга шатлык китерәләр, дуслыкларын, игътибарларын, ярдәмнәрен тәкъдим итәләр. Алар алмыйлар, ә киресенчә, бирәләр. Дөньяда иң зур куаныч, иң зур бүләк – синең башкаларны бәхетле итә алу мөмкинлегең булу. Ул һәркемгә бирелгән, әмма аны бөтен кеше дә белеп бетерми. Син тәүлек буе бәхетле була аласың, чөнки беркем дә башкаларга ярату, игътибар һәм җылылык бирүне чикли алмый.

- Минем монда каласым һәм Эльф буласым килә, – ди Сабый.

- Башкаларга күңел җылылыгын бирү, алар турында кайгырту өчен, кеше булу да җитә. Сиңа өеңә кайтырга вакыт җитте, – ди Эльф һәм, тылсымлы сүзен әйтеп, Сабыйны яңадан үз бүлмәсенә кайтара.

Сабый тизрәк яңа көн тууын теләп ята. Ул әти-әнисенә бүләккә рәсем ясый алачак, әбисенә булышачак, күрше малае өчен шаян хикәя язачак. Ямансулап утырырга вакыт булмаячак, бары тик тирә-юньдәгеләргә һәм Сабыйның үзенә дә күңел күтәренкелеге бирә торган шатлык һәм бәхет кенә булачак!



***Марина Фатеева***

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.